# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ялкын авыл җирлеге составына керүче Ялкын авылы

14 ноябрь 2019 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Ялкын авыл җирлеге составына керүче Караваево торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1. 2020 елда Ялкын авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:

- контейнер мәйданчыклары урнаштыру ;
-җирлек эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау;
- балалар уен мәйданчыгын төзекләндерү;
- торак пунктларның урамнарын карап тоту һәм төзекләндерү.

3. Әлеге карарны Ялкын авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Ялкын авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ялкын авыл җирлеге башлыгы И.В.Гущина